Филология секциясе «Татар һәм рус әдәбиятында терроризм прблемасының яктыртылуы»

Эзләнү эшенең темасы:

# *Татар әдәбиятында терроризм проблемасының яктыртылуы*

**Әхмәтова Арина**

ДБББУ “Советлар Союзы Герое Илдар Маннанов исемендәге 82 нче кадет мәктәбе”, 11 А сыйныфы, Яр Чаллы шәһәре

**Җитәкче**:

Гыйбадуллина Эльвира Равиловна,

Сафина Маһинур Нәҗиповна,

югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучылары

Яр Чаллы шәһәре, 2022 ел

**Эчтәлек**

I. Кереш. Террорчылык - куркыныч, террорчылык – афәт............................3-4

I. Төп өлеш. Татар әдәбиятында терроризм прблемасының яктыртылуы.

1. Муса Җәлилнең “Алтынчәч” поэмасы.........................................................5-7

2. Муса Җәлилнең “Алтынчәч” либреттосы .....................................................8

III. Йомгак...........................................................................................................9

Файдаланылган әдәбият исемлеге..................................................................10

## I. Кереш

Мин, Арина, 82нче кадет мәктәбенең 11нче сыйныфында укыйм.

Террорчылык. Нинди куркыныч, тетрәндергеч сүз. Ул кешедә курку хисе уята, чөнки сугыш, бәла-каза, гаепсез кешеләрнең үлеме белән бәйле. Террорчылыкның кайчан һәм кайда булуын беркем әйтә алмый. 2004нче елның 1нче сентябрендә Беслан шәһәрендә булган вакыйгалар һәр кешенең күңелендә мәңгегә уелып калыр.

Шушы вакыйгаларга бәйле рәвештә һәр елның 3 сентябрендә терроризм һәм экстремизмны кисәтү максатыннан мәктәпләрдә әлеге теманы яктырткан дәресләр, сыйныф сәгатьләре, түгәрәк өстәлләр, диспутлар, уеннар үткәрелә.

Безнең мәктәптә үткәрелгән сыйныф сәгате “Нәрсә ул террорчылык?” дигән

сорауга җавап эзләү белән башланды. Укучылар куелган сорауга өлешчә дөрес һәм төпле итеп җавап бирделәр. Кызыксынган укучыларның 1977нче елда Мәскәү метросында шартлау турында белүләре, Бесландагы вакыйгалар җаннарын тетрәндергәне ачыкланды. Дөрестән дә, террорчылык - куркыныч, террорчылык - афәт. Әңгәмә барышында укучыларга террорчылыкның сәясәт белән бәйләнгәнлеге, бу актларның халыкны куркыту, күпләп юк итү максатыннан оештырылуы турында сөйләнде.

Лидия Серованың "Терракты", "Еще вчера вы были живы..." Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Равил Фәйзуллин шигырьләре яңгыраганнан соң да сыйныф бүлмәсендә бик озак тынлык хөкем сөрде...

Димәк, халык фаҗигасе, кеше кайгысы,укучылар йөрәгенә барып җитте, күңелгә үтеп керде. Сыйныф сәгате мине битараф калдырмады, кулыма каләм алырга этәрде.

Бу эшнең **актуальлеге шунда**, терроризм проблемаларын ачыклау өчен Муса Җәлилнең “Алтынчәч” поэмасын өйрәнү.

Эшемнең **төп максаты**: татар әдәбиятында терроризм прблемасын яктырткан әсәрләрне барлау.

Максатыма ирешү өчен түбәндәге **бурычларны** хәл итүне үз алдыма куйдым.

1) Терроризмга карата нәфрәт хисе тәрбияләргә.

2) Татар әдәбиятында терроризм прблемасын яктырткан әсәрләр белән таныштырырга.

3) Яшәүнең кадерен белергә өйрәтергә.

**Гипотеза:** Татар әдәбиятында терроризм прблемасының чагылышы.

**Тикшерү объекты** булып Муса Җәлилнең “Алтынчәч” драматик поэмасын өйрәнү тора.

**Тикшерү предметы** - Муса Җәлилнең “Алтынчәч” драматик поэмасы.

Тикшерү-эзләү эше барышында әлеге **методлардан**, **алымнардан** файдаландым:

1. Муса Җәлилнең “Алтынчәч” драматик поэмасының эчтәлеге белән танышу.
2. Татар әдәбиятында терроризм прблемасын чагылдырылган әсәрләрне барлау.
3. Җыелган мәгълүматны туплау.

Минем эзләнү эшемнең **практик үзенчәлеге, әһәмияте** бик зур. Эзләнү эшемне тарих, әдәбият дәресләрендә кулланырга була.

Эшемнең төзелешенә килгәндә, ул кереш, төп, йомгак һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән тора. Керештә әлеге эшнең актуальлеген һәм максатын билгеләдек, төп бурычлар ачыкланды, тикшерү объекты күрсәтелде, безнең темага караган хезмәтләр барланды.

Эшемнең **фәнни-методологик нигезен** Муса Җәлилнең поэмасын өйрәнүгә багышланган материаллар тәшкил итте.

## II. Төп өлеш

1. Муса Җәлилнең "Алтынчәч" поэмасы

Эзләнү барышында татар әдәбиятында терроризм проблемасын яктырткан әсәрләрнең аз булуы ачыкланды. 20-30 нчы еллар әдәбиятында Флүс Латыйфиның "Кызыл террор", 30-40 нчы еллар әдәбиятында Муса Җәлилнең "Алтынчәч" поэмасын, соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрдән Тәлгать Галиуллинның "Төнге юллар" романын күрсәтергә мөмкин.

Саналган әсәрләр арасында миңа иң якыны – Муса Җәлилнең "Алтынчәч" поэмасы. Бу әсәр миңа 5нче сыйныфтан таныш. Әсәр белән сезне дә таныштырасым килә. Терроризм проблемасын әсрдән бергәләп эзлик.

"Алтынчәч" поэмасында туган илнең һәм туган халыкның читтән килгән Мөхәммәт хан кулыннан юкка чыгарыла язуы, әмма шул кыен хәлдән сакланып калуы тасвирлана. Тугыз җирле кабиләне чагылдыра торган тугыз атаклы батырның анасы Һәм тугыз турунның әбисе Тугзак ана, килмешәк ханның җәбереннән качып, Идел буена килеп утыра, шунда җәйләү кора. Уллары еракауда чакта, Тугзакның тугызынчы килене Каракаш ир бала таба. Балага Җик дип исем кушалар. Ир бала тууны зур бәйрәм-туй итеп үткәрәләр. Туйның кызган чагында, хан гаскәрләре җәйләүгә һөҗүм итәләр. Тугзак ана балаларын хан гаскәрләренә каршы аяусыз көрәшкә чакыра. Җикнең атасы Янбулат ханга каршы сугышка чыга, ләкин ханның дию пәһлеваны Кулупай кулыннан һәлак була. Хан Тугзакның барлык улларын үтерә, киленнәрен әсир итә. Тугзак, җирдә нәселен саклап калу өчен, килене Каракашны яшь баласы Жик белән җилкәнле каекта Иделгә төшереп агыза.

Каракаш (баласын кочаклап) туган ил белән бик авыр саубуллаша. Хан укчылары Каракашны үтерәләр, ә Тугзакның күзләрен сукырайтып, аяк табаннарын ярдырып, далага ялгыз чыгарып җибәрәләр. Шуның алдыннан Тугзак, килмешәк ханның язмышы ничек булачагын ачык итеп әйтеп бирә:

Күзләремне чукып алсаң да,

Табан асларымны ярсаң да,

Ил күзеннән кача алмассың.

Ялгыз турунымны табармын,

Үстерермен аны, карармын.

Аждаһаның башын өзәр ул,

Явыз ханның нәселен кисәр ул !

Тугзак образында яшәү һәм тормышның, халыкның мәңгелек булуына дан җырлана. Тугзак - киң күңелле, мәрхәмәтле, олы җанлы ана. Ул тормышны, ирекне, үзенең балаларын чын күңелдән, бөтен йөрәге белән ярата. Нәселе саклансын өчен һәм киләчәктә дошманнан үч алу өчен Җикне көймәгә утыртып качыра. Тугзак ана үз уллары өчен генә түгел, ә бөтен җәйләү халкы, бөтен халык өчен шәфкатьле ана. Халык Тугзакка туган ана, кадерле ана, шәфкатьле ана, газиз ана дип эндәшә. Тугзак бөтен йөрәге белән коллыкка, явызлыкка каршы, шуңа да ул халыкны азатлык һәм ирек өчен көрәшергә өнди:

Тез чүккәнче ханга кол булып,

Аягүрә сугышып үлегез! - дип, халыкны изге көрәшкә чакыра.

Җик атасыз-анасыз табигать кочагында кошлар, җәнлекләр белән бергә үсә, көчле баһадирга әйләнә. Аның турында “Мәргән батыр”  (төз атучы батыр, дастанда - Җик мәргән) дип, тирә-якка даны тарала. Җик туган җирен-илен эзли. Ханга ризасызлык күрсәтүче авылның ил агасы Бураш картның кызы Алтынчәч урманда җиләк җыйганда, Җикне очрата. Жик аны, ауга чыккан

хан егетләре кулыннан коткарып, авылына алып кайта. Җик ул үз халкының азатлыка илтүче батыр улы!

Әсәрдә Алтынчәчнең эчке дөньясы да, тышкы портреты да шактый тулы ачылган. Ул - матур, гүзәл кыз. Аның алтын чәчле булуы да шушы гүзәллекне тагын да арттыра. Алтынчәчне тышкы матурлык кына түгел, эчке матурлык та бизи. Ул ирекле, азат тормышны яратучы, саф һәм шат күңелле кыз. Анда халыкның барлык матур сыйфатлары: тырышлык һәм эчке матурлыгы да, батырлыгы да, кешелеклелеге дә, ирек сөючәнлеге дә чагыла.

## 2. Муса Җәлилнең “Алтынчәч” либреттосы

Муса Җәлил “Алтынчәч” драматик поэмасын либретто формасында 1935нче елның нояберендә яза башлый һәм 1936 елның августында тәмамлый. Әмма китап булып басылып чыкканчы, опера булып яңгыраганчы бу әсәргә шактый катлаулы юл үтәргә туры килә. Шагыйрь әсәрне кат-кат эшли, кат-кат төзәтә, һәр вариант саен поэманың эчтәлеге тирәнрәк ачыла, сәнгатьчә сыйфаты яхшыра. Композиторлар, язучылар үзләренең иптәшләрчә киңәшләре белән әсәрне төзәтергә, яхшыртырга ярдәм итәләр. Хәзерге көндә бу либретто нигезендә атаклы композиторыбыз Нәҗип Җиһанов тарафыннан язылган операны халыкка пропагандалау һәм аны сәхнәдә еш яңгырату тарихи дөреслекне торгызу, халыкка җиткерү һәм милләтебезне патриотик, музыкаль яктан тәрбияләү юлында бик зур бер алга атлау.

## III. Йомгак.

Чынлап та, Муса Җәлилнең “Алтынчәч” поэмасы бик үзенчәлекле. Андагы вакыйгалар тарихи чынбарлыктан ерак китмәгән сыман, ләкин шул ук вакытта терроризм  чалымнары да очрый. Мәсәлән, минемчә, Казан ханы Мөхәммәтнең Идел буендагы җирле халыкларны үзенә буйсындыруы, алардан көчләп ясак җыюы, алардан кол-крестьян ясавы – терроризм чагылышы. Ләкин халык терроризмга каршы чыга, яхшылык явызлыкны җиңә, уңай сыйфатлар өстен чыга.

Ләкин шулай да поэма азагында “Алтынчәч” поэмасы төрле милләт халыкларын туган ил һәм халык язмышы турында уйланырга, дошманнарга каршы азатлык өчен батырларча көрәшергә чакыра, халык көченә, киләчәккә тирән ышаныч тәрбияли. Шуңа әсәр төрле милләт халыклары өчен дә кызыклы, Алтынчәч белән Җикнең төрле каршылыкларны җиңеп бергә кушылуы бер үк дәрәҗәдә шатландыра.

Шулай итеп, Муса Җәлил, “Алтынчәч” поэмасында әкияти образларга төреп, терроризм проблемаларын чишүне бик оста куйган һәм аның чишелешен ышанычлы хәл итә алган.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: терроризмны булдырмас өчен, дәүләт хокук органнары тырышлыгы гына җитми, безнең үзебезгә һәрвакыт сизгер булырга кирәк. Бүгенге көндә җирле хакимият тә, җәмәгать органнары да терроризм һәм экстремизмга каршы бар тырышлыгын, бар көчен куя.

**Әдәбият исемлеге**


1. Алтынчәч. М. Җәлил, Казан “Татарстан китап нәшрияты”, 1975.
2. Сайланма әсәрләр. М.Җәлил, Казан “ТаРИХ”, 2004.
3. Шигырьләр һәм поэмалар. М. Җәлил, Казан “Татарстан китап нәшрияты”, 2006.
4. По следам поэта-героя. Р.Мустафин, Казань «Татарское книжное издательство», 1973.